

«Кече һәм урта эшкуарлык» милли проекты ярдәмендә Мордовиядә сыр пешерv vсеш ала. Берничә ел элек Теньгушево районы Шокша авылына Марина Перфильева белән Марат Беляков кvченгәннән сон тирәнлек vзгәрә. Алар монда мегаполистан тынлык һәм яхшы экология эзләп кvченгәннәр. Авылда йорт алалар, ә бераздан шәһәр халкы хужалык ача. Шулай итеп аларнын беренче ике кәҗәсе барлыкка килгән. Кvрше авыллардан килгән халык кайгыртучан терлекчеләр турында белә һәм торле сәбәпләр аркасында кәҗәне vзләре генә тота алмаган кешеләр Марина белән Маратнын яхшы кулларына бирә.      Авыл тормышы чын эшкуарлык эшчәнлегенә әверелә, һәм терлекчеләр «Мардарика» дип аталган кооператив тозиләр. Исемнен сере бер – берсенә һәм vз эшенә мәхәббәттә - Марина, Марат, дар һәм кәҗәләр. Бvген аларнын берничә дистә башлы зур кәҗә котvе бар, ә җәй зур савым очен бик яхшы вакыт. Аларнын соте юкка китми, ә витаминнарга бай сыр житештерvгә китә.
Әмма барысы да без сойләгәнчә гади тvгел. Мондый продуктны сертификациясез сатарга ярамый, ә документларны рәсмиләштерv процессы катлаулы һәм кvп вакыт таләп итә, һәм кесәгә дә суга. Проблеманы хәл итvдә «Минем бизнес» vзәге ярдәмгә килә. Марина бу vзәккә морәҗәгать итә һәм «Кече һәм урта эшкуарлык» милли проектын гамәлгә ашыру кысаларында, «Минем бизнес» vзәге эшне унышлы vстерv очен бушлай хезмәтләрнен зур спектрын кvрсәтә. Шулай Россия базарында Мордовия брендынын сырлары, чәе һәм суынган ите барлыкка килде.
Сыр тәмле продукт кына тvгел, ә чын файдалы матдәләр хәзинәсе дә. Моннан тыш, кәҗә сотенә аллергия азрак, майлылыгы кvбрәк булганы билгеле. Хәзер Марина һәм Марат 10 тордән артык сыр чыгаралар, һәр рецепт авторлык линейкасында. Тәмләткеч буларак бары тик табигый продуктлар гына: мускат, сарымсак, укроп, кунжут, чикләвекләр, помидор, кара борыч һәм башка кvп нәрсәләр.
Саклау вакытын озайту очен, сырны герметик банкаларга салалар. Бу формада ул ярты елга кадәр саклана ала. Шәһәрләрдә һәм кvрше тобәкләрдә искиткеч продукт турында белгәч, аны почта аша жибәрvне сорый башлыйлар. Шулай итеп, продуктны почта аша жибәрv идеясе туа, һәм бу ышанычлы да, куркынычсыз да. Сыр жиһазландырылган сыр заводында әзерләнә. Яна житештерv цехы барлык кирәкле техника һәм продукт олгергән махсус биналар белән жиһазландырылган.
Сырлар, vлән эчемлекләре һәм суындырылган ит чыгарудан тыш, Марина һәм Марат шулай ук мастер-класслар vткәрәләр. Бу да аерым йортта. Цех барлыкка килгәнче ул «Сырлы» дип аталган, ә хәзер чын музейга охшаган. Йортнын бизәлеше жаннын һәр почмагына кагыла. Тәрәзәләрдә борынгы пәрдәләр, остәлдә шокша милли солгесе, ояда кvкәйләр, тәмләткечләр салынган банкалар, самовар һәм башка кvп нәрсәләр. Моны һәркем кvрә ала: туристлар очен махсус турлар оештырылган. Кечерәк кунаклар белән эшмәкәр «биюче» салам кәжәләр ясау буенча мастер-класс vткәрә, тәвәккәлрәк кешеләр белән саву дәресләре vткәрелә. Котvлек буйлап йорv дә программада. Әлбәттә, хәтер фотосы булачак. Унай тәэсирләр генә калачак.

**Наилә НАСЫРОВА,** *фото «Темниковские известия»дэн*